ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

18.03.2026 г. Казань № 31-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 179-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 179-од номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең 2020 елның 19 октябрендәге 135-од номерлы, 2021 елның 24 июнендәге 69-од номерлы, 2021 елның 28 сентябрендәге 106-од номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуласында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары» сүзләре белән алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Хокук бүлеге җитәкчесенә Р.Ф. Шәяхмәтовка әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Г.Г.Мотыйгуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе
башлыгы Т.М.Галиев

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының Баш
ветеринария идарәсенең 2019 елның
12 ноябрендәге 179-од номерлы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты Баш
ветеринария идарәсенең 2026 елның
18 мартындагы 31-од номерлы
боерыгы редакциясендә)

## Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүче: Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле заты булмаган, законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә шәхси эшкуар буларак теркәлгән югары яисә урта ветеринария белеме булган физик зат (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүче исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкиле, мөрәҗәгать итүче) эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә, алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал) урнаштырыла.

1.4. Регламентта кулланыла торган шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

### 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба – Идарә).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән рәвештә таныклык;

2) Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклыкны яңадан рәсмиләштерү;

3) Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турындагы таныклыкның гамәлдә булуын туктату хакында әлеге Регламентка 7 нче кушымтада китерелгән рәвештәге карар;

4) әлеге Регламентка 8 нче кушымтада китерелгән форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклык рәсмиләштерелгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге пунктның 1 - 3 пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турында белешмәләр Идарәнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында бастырылган Ветеринария өлкәсе белгечләре реестрында мәҗбүри урнаштырылырга тиеш.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Идарәнең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (алга таба – Республика порталы) (https://uslugi.tatarstan.ru/) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең (алга таба – КФҮ) вәкаләтле хезмәткәренең мөһере һәм имзасы белән таныкланган, кәгазьдә бастырылган электрон документ нөсхәсе рәвешендә КФҮ алына ала.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен Идарә, КФҮ аша электрон документ яисә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

2.3.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ рәвешендә җибәрү дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны кәгазьдә бирү мөрәҗәгать итүче нәтиҗә бирүне сорап мөрәҗәгать иткән көнне, әмма дәүләт

хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көннән дә иртәрәк булмаган чорда гамәлгә ашырыла.

2.3.6. Мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язуын формалаштыру каралмаган.

2.3.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторларын күрсәтеп, шушы Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты.

2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Идарәгә шәхсән тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь вакыты алар Идарәдә теркәлгән көннән алып җиде эш көненнән дә артмый.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда яисә Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты эшләр номенклатурасы нигезендә гаризага Бердәм порталның яисә Республика порталының шәхси кабинетында чагылдырыла торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелгән көннән алып җиде эш көненнән дә артык түгел.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар КФҮ аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь срогы гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм аларны КФҮ теркәү өчен кирәкле документлар алынган көннән алып җиде эш көненнән артмый, шулай ук КФҮ регламентында каралган срок та исәпкә алына.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте Идарә тарафыннан түләүсез күрсәтелә.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

2.6.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда, мөрәҗәгать итүче турыдан-туры Идарәгә яисә КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәүгә алу чоры.

2.7.1. Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар бирелгән көнне Идарәнең вәкаләтле вазыйфаи заты гаризаны кабул итү датасын һәм аңа теркәп бирелгән документларны күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә хәбәр бирә.

2.7.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче аларны биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында

һәм электрон почта аша дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм документларның җибәрелгәнлеген раслый торган хәбәр ала, анда теркәү номеры һәм аларны тапшыру датасы күрсәтелгән була.

2.7.3. КФҮ шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар бирелгән көнне мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм документларның җибәрелгәнлеген раслаучы теркәү номерлы һәм гариза бирү датасы булган КФҮ язуы бирелә.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны Идарәгә Идарә белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тапшыру тәэмин ителә.

Идарәдә КФҮ аша килгән гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар кергән көнендә үк теркәлә.

2.7.4. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар ял (бәйрәм) көненнән соң икенче эш көнендә теркәлә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр Идарәнең рәсми сайтында, Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану һәм сыйфат күрсәткечләре Идарәнең рәсми сайтында, Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгече буларак теркәлү турында таныклык түбәндәге очракларда яңадан рәсмиләштерелә:

1) фамилиясен, исемен яисә атасының исемен (соңгысы – булган очракта) үзгәртү;

2) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның фактагы урыны адресына үзгәрешләр кертү.

2.10.3. Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгече буларак теркәлү турындагы таныклыкның гамәлдә булу вакыты түбәндәге очракларда туктатыла:

1) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруны туктату;

2) ветеринария эшчәнлеген туктату;

3) Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруны туктату;

4) Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче

органның һәм (яисә) оешманың вәкаләтле заты статусын алу.

2.10.4. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаны үтәү барышы һәм аның статусы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Идарә, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.10.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән очракта, шәхесне таныклый торган документ белешмәләре дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, гаризага гади электрон имза белән имза сала.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм системада теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең электрон документ рәвешендәге (электрон документ үрнәге) ышаныч кәгазе мондый документларны ясауга һәм имзалауга вәкаләтле булган затларның, шул исәптән нотариусның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныклана.

2.10.10. Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар

(документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре 50 Мбайттан артмаган үлчәмдә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

2.10.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә КФҮ үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булган очракта катнаша.

Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарлар КФҮ әлеге Регламентның 2.12.1 пункты таләпләре нигезендә кабул ителә.

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән КФҮ җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документларны бирү, шулай ук, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның мәгълүмат системаларыннан өземтәләрне кәгазь чыганакта төзү һәм таныклауны да кертеп, документлар бирү каралган.

2.10.12. Идарәнең рәсми сайтында, дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарындагы стендларда һәм КФҮ түбәндәге белешмә мәгълүмат урнаштырыла:

Идарәнең, шулай ук КФҮ урнашу урыны һәм эш графигы турында;

Идарәнең структур бүлекчәләренең белешмә телефоннары, шул исәптән телефон-автоинформатор номеры (булган очракта);

Идарәнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты, шулай ук электрон почта адресы һәм (яисә) кире элемтә рәвешләре.

2.10.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинеттан, КФҮ аша алынырга мөмкин.

2.10.14. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системалары:

1) Бердәм портал;

2) Республика порталы;

3) «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

2.10.15. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр Бердәм порталда, Республика порталында һәм Идарәнең рәсми сайтында урнаштырылган.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.11.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра торган документларга һәм мәгълүматка бүлеп, һәм мөрәҗәгать итүче үз инициативасы

белән тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш, әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән.

2.11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

2) документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

3) тапшырылган документларның яки белешмәләрнең хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – хезмәт күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта);

4) хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны билгеләнгән таләпләрне бозып электрон рәвештә бирү;

5) гаризаның рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталда яисә Республика порталында гаризаның интерактив рәвешендә кырларны тулысынча тутырмау;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплект белән тапшырылуы;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле булмаган республика башкарма хакимият органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылган очракта;

8) 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар формасы шушы Регламентның 9 нчы кушымтасында китерелгән.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклык бирүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

1) дәүләт хезмәтен сорап мөрәҗәгать иткән вакытка мөрәҗәгать итүче шәхси эшкуар булып саналмый;

2) мөрәҗәгать итүче Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры (алга таба – ШЭБДР) белешмәләре нигезендә ветеринария эшчәнлеген гамәлгә

ашырмый;

3) мөрәҗәгать итүченең ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган адресы Татарстан Республикасы территориясендә урнашмаган;

4) мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органның, оешманың вәкаләтле заты булып тора;

5) урта яисә югары ветеринария белеме булуы расланмаган;

6) мөрәҗәгать итүченең ышанычнамә нигезендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләте булмаган затның мөрәҗәгать итүе.

2.12.4. Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклыкны яңадан рәсмиләштерүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

1) дәүләт хезмәтен сорап мөрәҗәгать иткән вакытка мөрәҗәгать итүче шәхси эшкуар булып саналмый;

2) мөрәҗәгать итүче, ШЭБДР белешмәләре нигезендә, ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашырмый;

3) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) үзгәрүе расланмаган;

4) мөрәҗәгать итүче тарафыннан ветеринария эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган яңа адрес Татарстан Республикасы территориясендә урнашмаган;

5) мөрәҗәгать итүченең ышанычнамә нигезендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләте булмаган затның мөрәҗәгать итүе.

2.12.5. Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турындагы таныклыкның гамәлдә булмавы турында карар сорап мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

1) шәхси эшкуар буларак эшчәнлеген туктату турында белешмәләр расланмаган;

2) ветеринария эшчәнлеген туктату турындагы белешмәләр расланмаган;

3) Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген туктату турындагы белешмәләр расланмаган;

4) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органның, оешманың вәкаләтле зат статусын алуы турындагы белешмәләр расланмаган.

5) мөрәҗәгать итүченең ышанычнамә нигезендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләте булмаган затның мөрәҗәгать итүе.

2.12.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең категорияләрен (билгеләрен) исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

2.12.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, Идарә мөрәҗәгать

итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп, хәбәр итә.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) үткәрелә торган административ процедураны, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң мөрәҗәгать итүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны) бүлүне күздә тоткан административ процедураны, мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатлау рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын гамәлгә ашыру каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ процедуралар башкарыла:

1) мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.3. Дәүләт хезмәте алгарышлы (проактив) режимда күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары.

4.1. Техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаның статусы үзгәрүе (гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү турында; гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны карау турында; дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен күрсәтү турында), шулай ук мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтелгән этабында санап үтелгән ысулларның берсе белән башкарырга тиешле алда торган адымнар һәм гамәлләр турында хәбәр ителә:

- Бердәм портал ярдәмендә;
- Республика порталы аша;
- башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

4.2. Бердәм порталда һәм Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетында дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында статуслар урнаштырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе, мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйсез рәвештә, урнаштырыла.

Татарстан Республикасы
территориясендә ветеринария
өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге
белән шөгыльләнүче
ветеринария өлкәсе белгечләрен
теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Дәүләт хезмәте – Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү.

2. ШЭБДР – шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры.

3. Бердәм портал – Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/).

4. БИАС – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы.

5. Мөрәҗәгать итүче – югары яисә урта ветеринария белеме булган, Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керә торган органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле заты булмаган, Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче шәхси эшкуар.

6. КФҮ – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге.

7. Бүлек – Идарәнең ветеринария эшен оештыру бүлеге.

8. Мөрәҗәгать итүченең вәкиле – Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат.

9. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар проекты – дәүләт хезмәте күрсәтү турында шушы Регламентның 2.3.1 пунктының 1-3 пунктчаларында каралган карар проекты.

10. Регламент – Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты.

11. Республика порталы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/).

12. Идарә – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе.

13. 63-ФЗ номерлы федераль закон – «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон.

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| Т/с | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклык | Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле заты булмаган, законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә шәхси эшкуар буларак теркәлгән югары яисә урта ветеринария белеме булган физик зат | 1А |
| | | Законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат | 2А |
| 2 | Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклыкны яңадан рәсмиләштерү | Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле заты булмаган, законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә шәхси эшкуар буларак теркәлгән югары яисә урта ветеринария белеме булган физик зат | 1Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат | 2Б |
| 3 | Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турындагы таныклыкның гамәлдә булуын туктату хакындагы карар | Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле заты булмаган, законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә шәхси эшкуар буларак теркәлгән югары яисә урта ветеринария белеме булган физик зат | 1В |
| | | Законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат | 2В |

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| Т/с | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләренең шифрын ачу, төркемнән документлар саны | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| 1. Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырган документлар һәм мәгълүмат | | | |
| 1. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) | Идарә, Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ | Идарә, КФҮ |
| 3. | 2А, 2Б, 2В | Мөрәҗәгать итүче вәкиленең мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документ | Идарә, Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |
| 4. | 1А, 2А, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керә торган органның, оешманың вәкаләтле заты булуын раслый торган документ | Идарә, Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |
| 2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документлар | | | |
| 1. | 1А, 2А | Югары яисә урта ветеринария белеме турында документ (Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт) | Идарә, Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | ШЭБДР алынган белешмәләр (Россия Федераль салым хезмәте) | Идарә, Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |
| 3. | 2А, 2Б, 2В | Нотариаль ышанычнамә турында белешмәләр (Федераль нотариаль палата, Бердәм нотариат мәгълүмат системасы) | Идарә, Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |
| 4. | 1Б, 2Б | Фамилиясен, исемен яисә атасы исемен үзгәрткән затлар өчен фамилиясен, исемен яисә атасы (соңгысы - булган очракта) исемен үзгәртү турында белешмәләр (Россия Федераль салым хезмәте) | Идарә, Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| Т/с | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы | Нигезләр исемлеге |
|---|---|---|
| 1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | | |
| 1. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булган очракта |
| 3. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Бирелгән документларның яки белешмәләрнең хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – хезмәт күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 4. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Хезмәт күрсәтү турындагы гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада тапшырылуы |
| 5. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Гаризаның рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталда яисә Республика порталында гаризаның интерактив рәвешендә кырларны тулысынча тутырмау |
| 6. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тапшыру |
| 7. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле булмаган республика башкарма хакимият органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылган очракта |
| 8. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, | 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында |

| | | |
|---|---|---|
| | 1В, 2В | билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве |
| 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләрнең тулы исемлеге | | |
| 1. | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган | |
| 3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | | |
| 3.1. Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклык бирүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Дәүләт хезмәтен сорап мөрәҗәгать иткән вакытка мөрәҗәгать итүче шәхси эшкуар булып саналмый |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүче Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры белешмәләре нигезендә ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашырмый |
| 3. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүченең ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган адресы Татарстан Республикасы территориясендә урнашмаган |
| 4. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органның, оешманың вәкаләтле заты булып тора |
| 5. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Урта яки югары ветеринария белеме булуы расланмаган |
| 6. | 2А, 2Б, 2В | Мөрәҗәгать итүченең ышанычнамә нигезендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләте булмаган затның мөрәҗәгать итүе |
| 3.2. Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклыкны яңадан рәсмиләштерүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Дәүләт хезмәтен сорап мөрәҗәгать иткән вакытка мөрәҗәгать итүче шәхси эшкуар булып саналмый |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүче Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры белешмәләре нигезендә ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашырмый |
| 3. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) үзгәрүе расланмаган |
| 4. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүченең ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган адресы Татарстан Республикасы территориясендә урнашмаган |
| 5. | 2А, 2Б, 2В | Мөрәҗәгать итүченең ышанычнамә нигезендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләте булмаган затның мөрәҗәгать итүе |
| 3.3. Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турындагы таныклыкның гамәлдә булмавы турында карар сорап мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |

| | | |
|---|---|---|
| 1. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Шәхси эшкуар буларак эшчәнлеген туктату турында белешмәләр расланмаган |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Ветеринария эшчәнлеген туктату турындагы белешмәләр расланмаган |
| 3. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген туктату турындагы белешмәләр расланмаган |
| 4. | 1А, 2А, 1Б, 2Б, 1В, 2В | Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органның, оешманың вәкаләтле зат статусын алуы турындагы белешмәләр расланмаган |
| 5. | 2А, 2Б, 2В | Мөрәҗәгать итүченең ышанычнамә нигезендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләте булмаган затның мөрәҗәгать итүе |

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Формасы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать

Мөрәҗәгать итүегезнең максатын сайлагыз* (V тамгасын куегыз):

☐ Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгече буларак теркәвегезне сорыйм

______________________________________________.
Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

☐ Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклыкны яңадан рәсмиләштерүегезне сорыйм

______________________________________________.
Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

☐ Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турындагы таныклыкның гамәлдә булуын туктатуыгызны сорыйм

______________________________________________.
Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

шәхесне таныклаучы документның реквизитлары: ____________________
______________________________________________

яшәү (тору) урыны буенча теркәлү адресы: ____________________
______________________________________________

ышанычнамә буенча вәкил ______________________________
Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

______________________________________________

шәхесне таныклаучы документның реквизитлары: ____________________
______________________________________________

яшәү (тору) урыны буенча теркәлү адресы: ____________________
______________________________________________

ИНН: ____________________ ОГРНИП: ____________________

ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны адресы: ____________________
______________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

телефон номеры: __________________________________________________________

электрон почта адресы: __________________________________________________

ветеринария белеме булу турында белешмәләр: ____________________________

белем дәрәҗәсе: ________________________________________________________

мәгариф оешмасының тулы исеме: ____________________________

________________________________________________________________________________

мәгариф турындагы документ бланкының сериясе, номеры: ________________________________

бирелү датасы:

Әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

Дәүләт хезмәтен максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, «Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә шәхси белешмәләрне эшкәртү, алардан файдалану, аларны тарату (шул исәптән тапшыру), шулай ук аларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкаруга үземнең риза булуымны, шулай ук минем исемнән эш итүче вәкилнең риза булуын раслыйм.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен түбәндәге ысул белән бирүне сорыйм (мөрәҗәгать итүче ихтыяры буенча бер вариант сайлана):

- ☐ Бу адрес буенча урнашкан КФҮ аша: ________________________________
- ☐ электрон рәвештә Бердәм порталдагы шәхси кабинетка җибәрергә
- ☐ электрон рәвештә Республика порталындагы шәхси кабинетка җибәрергә
- ☐ Идарәдә

Кушымта:

| ________________ | ________________________ | _____________________ |
|---|---|---|
| Дата | Гариза бирүченең имзасы | Имзаның аңлатмасы |

"*" дип билгеләнгән кырларны тутыру мәҗбүри була

-----------------------------------------------------------------------------------------------------------

*(кисеп алу сызымы)*

## ХӘБӘР

Гариза 20_____ елның «___» _______________ кабул ителде.
Теркәү № ______________________________

Гаризаны кабул итте: __________________________________________________________

(гаризаны кабул иткән КФҮ хезмәткәренең вазыйфасы, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) һәм имзасы)

Гариза һәм документлар 20____ елның «___» _______________ кабул ителде.
Теркәү № ______________________________

Гаризаны һәм
документларны кабул итте: ________________________________________________

(гаризаны кабул иткән Идарә белгеченең вазыйфасы,
Ф.И.А. (булган очракта) һәм имзасы)

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Формасы

______________________________________________
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклык № ____________ _________________

Бирелде: Шәхси эшкуар________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
__________________________________________________________с
алым түләүченең идентификация номеры (ИНН) ______________________________,
шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры (ОГРНИП)) ____________________,
ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыру адресы: _____________________________.
ОКВЭД коды: ______________________.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________<br>Карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы | (Электрон имза сертификаты турында белешмәләр) | ______________________<br>Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) |

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Формасы

___________________________________________________________

карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Кемгә:

______________________________

______________________________________

______________________________________

______________________________________

Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), шәхесне таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, кем тарафыннан бирелгән, бирү датасы

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турында таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында карар

№ ____________ _________________

Алынган № ________ гариза нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечен теркәү турындагы таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында карар кабул ителде №________________ _____________, чөнки:

- _________________________________________________________________.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | (Электрон имза сертификаты турында белешмәләр) | ________________________ |
| Карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы | | Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) |

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Формасы

______________________________________________________________________________
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Кемгә:

___________________________________
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), шәхесне таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, кем тарафыннан бирелгән, бирү датасы

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар
№ _________________ _________________

№ ________________ ________________ гаризаны карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, сәбәпләре:
1. ______________________;
2. ______________________.

Күрсәтелгән хокук бозулар бетерелгәннән соң, сез дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга шикаятьне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә җибәрү юлы белән судка кадәр, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

| | | |
|---|---|---|
| _________________________ | (Электрон имза сертификаты турында белешмәләр) | ____________________________ |
| Карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы | | Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) |

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

Формасы

________________________________________________________________________

карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Кемгә:

________________________________

________________________________________

________________________________________

________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), шәхесне таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, кем тарафыннан бирелгән, бирү датасы

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар № ________________ ____________________

Кергән, теркәлгән № ________________ ____________________ гариза нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде.

Гаризаны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны аңлату:

1)

2)

Әлеге хокук бозулар бетерелгәннән соң, сез хезмәт күрсәтү турындагы гариза белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга шикаятьне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә җибәрү юлы белән судка кадәр, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

| | | |
|---|---|---|
| ________________________ | (Электрон имза сертификаты турында белешмәләр) | ________________________ |
| Карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы | | Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) |